ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 март 2019ел № 1237

Башкарма комитетның «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 1 ноябрендәге 5748 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 1 ноябрендәге 5748 нче карарына (Башкарма комитетның 2017 елның 16 мартындагы 1309 нчы, 2018 елның 22 февралендәге 900 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү» муниципаль программасын тормышка ашыру буенча чараларны финанслауны шәһәр бюджетының «Мәгариф» бүлегендә каралган акчалар хисабына 2017 елга – 5558254,56 мең сум, 2018 елга – 6085281,24 мең сум, 2019 елга – 6041389,68 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә ««Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 (мең сум) | 2018 (мең сум) | 2019 (мең сум) | Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум) |
| | Муниципаль бюджет | 5558254,56 | 6085281,24 | 6041389,68 | 17684925,48 |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Барысы | 5558254,56 | 6085281,24 | 6041389,68 | 17684925,48 |

- 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 бүлек. Программаны ресурлар белән тәэмин итү

2017-2019 елларга программаны финанслау күләме 17684925,48 мең сум тәшкил итә.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет акчалары:

Чор өчен барлыгы 17684925,48 мең сум, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча:

2017 елга – 5558254,56 мең сум, 2018 елга – 6085281,24 мең сум, 2019 елга – 6041389,68 мең сум.»;

- 9 нчы бүлекне 1 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

- 10 нчы бүлекне 2 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 13 мартындагы
1237 нче карарына
1 нче кушымта

9 бүлек. Муниципаль программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| Төп чараларның исеме | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) | | | | Башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | |
| | | | | | | Финанслау чыганагы - муниципаль бюджет | | | | |
| Максатның исеме: кеше потенциалын формалаштыру һәм шәһәрне социаль яңарту нигезе буларак, Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү өчен аның барлык дәрәҗәләрендә сыйфатлы белем бирүне тәэмин итү һәм оптималь шартлар тудыру.<br>Ярдәмче программа: Мәктәпкәчә белем бирү<br>Бурычның исеме: мәктәптә уңышлы укыту нигезе буларак, балаларны физик һәм психологик яктан үстерү өчен мәктәпкәчә белем бирүнең кирәкле шартларын тәэмин итү. | | | | | | | | | | |
| Һәркем ала алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем бирүне тәэмин итү | «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы аша 2,5 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларны мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар белән тәэмин итү (%) | 100 | 100 | 100 | 100 | 2495532,84 | 2355747,54 | 2457992,41 | 2545124,76 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең мәктәпкәчә белем бирү бүлеге |
| Инклюзив белем бирүне оештыру | Мәктәпкәчә белем бирүнең яңа формаларын кертеп, инклюзив, интегратив | 87 | 87 | 88 | 89 | 11311,4 | 11424,5 | 11538,8 | 11654,1 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | һәм махсус белем бирүне үстерү юлы белән 3 яшьтән башлап инвалид балаларны һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны мәктәпкәчә белем алуга җәлеп итү (%) | | | | | | | | | эшләү идарәсенең мәктәпкәчә белем бирү бүлеге |
| Ярдәмче программа: Гомуми белем бирү<br>Бурычның исеме: гомуми белем бирүнең барлык дәрәҗәләрендә белем бирү программаларының дәвамчанлыгы нигезендә белем бирү сыйфатын тәэмин итү өчен шартлар тудыру. | | | | | | | | | | |
| Башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең Федераль Стандартын тормышка ашыру | - укучыларны гомуми белем бирүнең Федераль стандартына җәлеп итү (%);<br>- татар балаларын туган телдә белем алуга җәлеп итү (%);<br>- чыгарылыш сыйныф укучыларының гомуми санына карата рус теле һәм математика буенча ТДИ тапшырган чыгарылыш сыйныф укучыларының өлеше;<br>- чыгарылыш сыйныф укучыларының гомуми санына карата рус теле һәм математика буенча БДИ тапшырган чыгарылыш сыйныф | 100<br>50,5<br>99,4<br>100 | 100<br>50,5<br>98,7<br>100 | 100<br>50,5<br>100<br>100 | 100<br>50,5<br>100<br>100 | 2220202,71 | 2428610,11 | 2812188,84 | 2775597,35 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең гомуми белем бирү бүлеге |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | укучыларының өлеше; | | | | | | | | | |
| | - дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре буенча аттестат алган 9 нчы сыйныф укучыларының чагыштырма авырлыгы (%); | 99,4 | 97 | 100 | 100 | | | | | |
| | - дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре буенча аттестат алган 11 сыйныф укучыларының чагыштырма авырлыгы (%); | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | | |
| | - «яхшы» һәм «бик яхшы» билгеләренә укучыларның чагыштырма авырлыгы (%); | 53,8 | 53,9 | 54,0 | 54,0 | | | | | |
| | - 9 сыйныфларда татар теле буенча БРТ биремнәрен башкаруның уртача күрсәткече (%); | 73,8 | 73,8 | 73,8 | 73,8 | | | | | |
| | - укучыларны профиль алды һәм профильле укыту программаларына җәлеп итү (%); | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | | |
| | - кайнар ризык белән тәэмин ителгән укучыларның чагыштырма авырлыгы (%); | 90 | 90,5 | 91 | 92 | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | - спорт-сәламәтләндерү чараларына җәлеп ителгән укучыларның чагыштырма авырлыгы (%);<br>- сыйныфларның фактик тулылыгының нормативларга мөнәсәбәте | 100<br><br>100 | 100<br><br>100 | 100<br><br>100 | 100<br><br>100 | | | | | |
| 9, 11 сыйныфларда БДИ, ТДИ формасында дәүләт йомгаклау аттестациясен оештыру һәм үткәрү өчен шартлар тудыру (имтиханнарны кабул итү пунктларын җиһазландыру, дәүләт йомгаклау аттестациясе материалларын транспортлау) | 9, 11 (12) сыйныфларда имтиханнар үткәрү пунктлары буларак җиһазландырылган белем бирү оешмалары саны | 20 | 19 | 19 | 19 | 2500,0 | 1004,76 | 967,98 | 0 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең гомуми белем бирү бүлеге<br><br>Муниципаль гомуми белем бирү оешмалары |
| Бурычның исеме: белем бирүнең барлык дәрәҗәләрендә белем бирү процессына психологик ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәле системасын булдыру. | | | | | | | | | | |
| Мәҗбүри социаль изоляция шартларында | Индивидуаль медицина-социаль һәм психологик-педагогик ярдәм белән тәэмин | 100 | 100 | 100 | 100 | 6403,98 | 6861,55 | 8633,01 | 8515,41 | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| калган мәктәп яшендәге балаларга психологик-педагогик ярдәм күрсәтү, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны укыту өчен шартлар тудыру | ителгән аерым белем бирү ихтыяҗлары булган балалар өлеше (%) | | | | | | | | | эшләү идарәсе<br><br>«85 нче психологик-медицина-социаль ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе |
| Бурычның исеме: шәһәрдә интеллектуаль һәм иҗади эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә сәләтле балаларны һәм талантлы яшьләрне ачыклау, үстерү һәм аларга ярдәм күрсәтүнең бердәм системасын булдыру өчен уңай шартлар тудыруны тәэмин итү. | | | | | | | | | | |
| Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасында катнашу | Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының региональ этабы җиңүчеләре һәм призерлары өлеше (%) | 48 | 48 | 49 | 49 | 2000,0 | 2311,97 | 2025,94 | 0 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең гомуми белем бирү бүлеге<br><br>Муниципаль гомуми белем бирү оешмалары |
| Лицей-интернатларда балалар өчен белем һәм тәрбия бирү программасын | Белем бирү оешмаларының Федераль һәм региональ исемлек нигезендә укыту-методик әсбаплар һәм | 95 | 96 | 97 | 98 | 98629,89 | 119314,84 | 81253,10 | 88747,46 | «79 нчы лицей-интернат» муниципаль бюджет гомуми белем |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| тормышка ашыру | җиһазлар белән тәэмин ителеше (%) | | | | | | | | | бирү учреждениесе<br><br>«Г. Акыш исемендәге 84 нче лицей-интернат» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе |
| - «Һөнәрләр дөньясы»;<br>- «Вожатыйлар осталыгы»;<br>- «Ел укучысы»;<br>- «Иң яхшы постта торучы»;<br>- «Хокук бозуларны профилактикалау буенча иң яхшы мәктәп отряды»;<br>- «Иң яхшы тимурчылар отряды» шәһәр конкурсларын оештыру һәм үткәрү | Төрле дәрәҗәдәге конкурсларда, фестивальләрдә, фәнни һәм иҗади конференцияләрдә катнашучы белем бирү оешмалары укучыларының өлеше (%) | 18 | 19 | 20 | 21 | 1415,79 | 1558,49 | 0 | 0 | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе<br><br>Муниципаль гомуми белем бирү оешмалары |

Ярдәмче программа: Өстәмә белем бирү
Бурычның исеме: шәхеснең иҗади индивидуальлеген үстерү һәм социализацияләү өчен шартлар тудыру.

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Сәнгать-эстетика юнәлешендәге оешмалар тарафыннан өстәмә белем бирү хезмәтләре күрсәтү | Төрле дәрәҗәдәге фестиваль һәм конкурсларда җиңүчеләр һәм призерлар өлеше (%) | 16 | 18 | 20 | 21 | 293847,61 | 374562,59 | 427077,31 | 412321,62 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең тәрбия һәм өстәмә белем бирү бүлекчәсе<br><br>Сәнгать-эстетика юнәлешендәге муниципаль өстәмә белем бирү учреждение ләре |
| Өстәмә белем бирү учреждениеләре тарафыннан төрле юнәлештәге программаларны тормышка ашыру | - укучыларны балаларга һәм яшьләргә өстәмә белем бирү программаларына җәлеп итү (%);<br>- укучыларны балалар техник иҗатына җәлеп итү (%) | 100<br><br>18 | 100<br><br>19 | 100<br><br>20 | 100<br><br>21 | 149115,83 | 177648,13 | 198680,49 | 188684,63 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең тәрбия һәм өстәмә белем бирү бүлекчәсе<br><br>Күп профильле юнәлештәге муниципаль өстәмә белем бирү учреждение |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | ләре |
| Укыту-методик ярдәм<br>Бурычның исеме: белем бирү процессын укыту-методик яктан тәэмин итү, уку-укыту процессын оештыруга яңа формалар һәм технологияләр кертүне активлаштыру. | | | | | | | | | | |
| Шәһәрнең белем бирү оешмаларында фәнни-консультация эшен, инновацияләр, фәнни тикшеренү методлары буенча семинарлар оештыру | - белем бирүдә мәгълүмати-коммуникатив технологияләрдән файдаланучы педагогларның чагыштырма авырлыгы (%);<br>- фәнни-эксперимент эшчәнлегендә, инновацион проектларда катнашучы педагоглар өлеше (%) | 100<br><br>15 | 100<br><br>18 | 100<br><br>20 | 100<br><br>21 | 10459,34 | 11947,71 | 11224,60 | 10744,35 | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе<br><br>«Мәгълүмати-методик үзәк» муниципаль бюджет учреждениесе |
| Тармакны кадрлар белән тәэмин итү<br>Бурычның исеме: Тармакның компетентлы, югары квалификацияле белгечләргә ихтыяҗын тәэмин итү. | | | | | | | | | | |
| Педагогларның квалификациясен күтәрү эшен оештыру | - квалификация категорияләре булган педагоглар өлеше (%);<br>- югары белемле педагогларның гомуми һәм урта гомуми белем дәрәҗәсендә чагыштырма | 79<br><br>100 | 82<br><br>100 | 82<br><br>100 | 82<br><br>100 | 7144,8 | 0 | 0 | 0 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең оештыру-педагогик тәэмин итү |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | авырлыгы (%) | | | | | | | | | һәм социаль яклау бүлеге |
| Педагоглар арасында<br>- «Ел укытучысы»;<br>- «Ел педагог-психологы»;<br>- «Ел сыйныф җитәкчесе»;<br>- «Өстәмә белем бирү педагогы» конкурслары оештыру һәм үткәрү | Һөнәри осталыкны күтәрү буенча конкурсларда, конференцияләрдә катнашучы педагоглар өлеше (%) | 30 | 30 | 31 | 32 | 643,03 | 867,69 | 0 | 0 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең оештыру-педагогик тәэмин итү һәм социаль яклау бүлеге |
| Ярдәмче программа: Производство-техник тәэмин итү.<br>Бурычның исеме: муниципаль белем бирү оешмалары эшчәнлегенең оптималь шартларын булдыру. | | | | | | | | | | |
| Муниципаль белем бирү оешмалары биналарын, корылмаларын һәм инженерлык коммуникацияләрен капиталь һәм агымдагы ремонтлауга агымдагы һәм перспектив планнарны эшләү, мәгариф оешмаларындагы авария хәлләрен | - капиталь һәм агымдагы ремонт үткәрелгән мәгариф учреждениеләре өлеше (%); | 100 | 100 | 100 | - | 60991,98 | 66394,67 | 73698,76 | - | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| үз вакытында бетерүне тәэмин итү, шәһәрнең муниципаль оешмаларын транспорт белән тәэмин итү | - үзәк тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр белән тәэмин ителгән кулланучылар өлеше (%) | | 70 | 100 | - | | | | | |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 13 мартындагы
1237 нче карарына
2 нче кушымта

10 бүлек. Программаны финанс ягыннан тәэмин итү чыганаклары һәм күләме

Күрсәтелгән бүленеш прогноз характерына ия һәм Яр Чаллы шәһәре бюджеты проектларын формалаштырганда билгеләнгән тәртиптә ел саен төгәллек кертелергә тиеш.

| Программаның бүлекләре | Еллар буенча финанс ягыннан тәэмин итү | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Финанслау чыганагы – муниципаль бюджет (мең сум) | | | |
| | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
| Гомуми белем бирү системасы | 2233906,33 | 2434353,02 | 2815182,76 | 2775597,35 |
| Интернатлар системасы | 98629,89 | 119314,84 | 81253,10 | 88747,46 |
| Күп профильле оешмаларда өстәмә белем бирү системасы | 149115,83 | 177648,13 | 198680,49 | 188684,63 |
| Сәнгать-эстетика юнәлешендәге өстәмә белем бирү системалары | 293847,61 | 374562,59 | 427077,31 | 412321,62 |
| Укыту-методик ярдәм күрсәтү системалары | 10459,34 | 11947,71 | 11224,60 | 10744,35 |
| Психологик-медицина-педагогик ярдәм күрсәтү системасы | 6403,98 | 6861,55 | 8633,01 | 8515,41 |
| Мәктәпкәчә белем бирү системалары | 2506844,24 | 2367172,04 | 2469531,21 | 2556778,86 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Производство-техник тәэмин итү хезмәте | 60991,98 | 66394,67 | 73698,76 | - |
| Барлыгы: | 5360199,2 | 5558254,56 | 6085281,24 | 6041389,68 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе




Г.К. Әхмәтова